**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәсгут авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәсгут авылы №111 « 13 » декабрь 2018 ел

**2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты турында**

**Статья 1**

1. 2019 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 5 974,4 мең сумм итеп;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 5 974,4 мең сумм итеп;

3) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп.

2. 2020 елга һәм 2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 6 089,7 мең сум һәм 2021 елга 6 097,9 мең сум итеп;

2) 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6 089,7 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 150,1 мең сум итеп һәм 2021 елга 6 097,9 мең сум шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 300,4 мең сум итеп;

3) 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум һәм 2021 елга 0,0 мең сум итеп.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга

**Статья 2**

1. 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге дәүләт гарантияләре буенча бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге дәүләт гарантияләре буенча бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

